**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 26 июнендәге 2714 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Мәскәү районындагы Тверь урамы буенча җир кишәрлекләренә ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 63 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:50:100303:4, 16:50:100303:12, 16:50:100303:15;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Мәскәү районы, Тверь урамы;
- билгеләү вакыты: электр челтәре хуҗалыгы объекты – җирле әһәмияттәге ТП-761 трансформаторлы подстанция урнаштыру;
- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләүгә нигезләр: гариза бирүченең мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы (2018 елның 21 декабрендәге редакциядә) «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын билгеләү тәртибе һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартлары турында» карары, Казан шәһәр Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, җирле әһәмияттәге ТП-761 трансформатор подстанциясенә милек хокукы теркәлгән (2001 елның 26 декабре, №16-50.3-23.2001-1288.3)

2. Әлеге карарның 1 һәм 2 номерлы кушымталарында күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән файдалануның рөхсәт ителгән төре нигезендә файдалану мөмкин булмаган яисә сизелерлек кыенлашкан вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут чорына туры килә дип билгеләргә.

3. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

4. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтеп бетергәннән соң яисә, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда, җир кишәрлегендә ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, өч айдан да соңга калмыйча аннан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 26 июнендәге
2714 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Кадастр номерлары 16:50:100303:4, 16:50:100303:12, 16:50:100303:15 булган җир кишәрлекләренең бер өлешендә ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштабы 1:500
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:100303 | кадастр кварталы |
| 16:50:100303:4, 16:50:100303:12, 16:50:100303:15 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

_________________________